# ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР

Белем һәм күнекмәләрне ныгыту этабы

# Дәрес максаты

1) *Белем бирү* – тезмә кушма җөмләләр турында гомуми мәгълүмат бирү;
2) *Күнекмә формалаштыру* – тезмә кушма җөмләләрне аера белү, аларга синтаксик анализ ясау һәм сөйләмдә куллану күнекмәләрен булдыру;
3) *Тәрбияви максат* – төрле мәкаль-әйтемнәр һәм хәдисләр ярдәмендә укучыларда хезмәткә хөрмәт, тырышлык, сәламәтлеккә сакчыл караш кебек әхлакый сыйфатларны тәрбияләү.

# Тест сораулары

1. Кайсы билгеләмә тезмә кушма җөмләләргә туры килә?

а) үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән тора;

ә) гади җөмләләре үзара кушымчалар ярдәмендә бәйләнә;

б) гади җөмләләре үзара янәшә тору юлы белән бәйләнә;

в) үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән тора.

- 2. Теркәгечле тезмә кушма җөмләнең гади җөмләләре нинди чаралар ярдәмендә бәйләнә?
- а) интонация  ярдәмендә;
- ә)    тезүче теркәгечләр белән;
- б) теркәгеч сүзләр ярдәмендә;
- в) ияртүче теркәгечләр ярдәмендә.

- 3. Теркәгечле тезмә кушма җөмләнең гади җөмләләре арасында нинди тыныш билгесе куела?
- а) нокталы өтер;
- ә)  өтер;
- б) сызык;
- в) ике нокта.

- 4. *Бай дигән даны бар, тик чыкмаган җаны бар* дигән җөмләнең төрен билгеләргә.
- а) гади җөмлә;
- ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә;
- б) иярченле кушма җөмлә;
- в) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә.

- Теркәгечсез тезмә кушма җөмләнең гади җөмләләренең бәйләүче чаралары?
- а) кушымчалар;
- ә) мөнәсәбәтле сүзләр;
- б)   санау һәм каршы кую интонациясе;
- в) янәшә тору юлы.

- *Ашарга чакырдылар кермәдем* җөмләсендә нинди тыныш билгесе куела?
- а) өтер;
- ә) сызык;
- б) ике нокта;
- в) тыныш билгесе куелмый.

Бирелгән җөмләләргә синтаксик анализ ясарга:

- *1) Тугры бул, холкың да кешеләргә изгелек эшли торган булсын.*
- *2) Матурлык түйда кирәк, ә мәхәббәт көн дә кирәк.*
- *3) Хезмәтнең тире ачы – җимеше татлы.*
- *4) Сәламәтлек – җәүһәр, ләкин ул тиз югала.*
- *5) Эшләгез, булдыра алган һәркемнең эшләре дә уң булыр.*

- Дөрес җаваплар:
- *1) Тугры бул, холкың да кешеләргә изгелек эшли торган булсын*.
- Бу теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, ике җөмләдән тора: беренчесе – *Тугры бул*, икенчесе – *холкың да кешеләргә изгелек эшли торган булсын*. Бәйләүче чара – санау интонациясе.
- Схемасы: [1] , [2].

- 2) *Матурлык түйдә кирәк, ә мәхәббәт көн дә кирәк.*
- Бу теркәгечле тезмә кушма җөмлә, беренче җөмлә – *Матурлык түйдә кирәк*, икенчесе – *ә мәхәббәт көн дә кирәк*. Бәйләүче чара – *ә* каршы куючы теркәгече.
- Схемасы: [1], ә [2].

- 3) *Хезмәтнең тире ачы – җимеше татлы*.
- Бу теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. Беренче җөмлә –*Хезмәтнең тире ачы*, икенчесе – *җимеше татлы*. Бәйләүче чара – каршу кую интонациясе.
- Схемасы: [1] - [2].

- 4) *Сәламәтлек – җәүһәр, ләкин ул тиз югала.*
- Бу теркәгечле тезмә кушма җөмлә, беренче җөмләсе -- *Сәламәтлек – җәүһәр*, икенчесе -- *ләкин ул тиз югала.* Бәйләүче чара – *ләкин* каршы кую теркәгече.
- Схемасы: [1], *ләкин* [2].

- 5) *Эшләгез, булдыра алган һәркемнең эшләре дә уң булыр.*
- Бу теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, беренче җөмләсе – *Эшләгез,* икенчесе -- *булдыра алган һәркемнең эшләре дә уң булыр.* Бәйләүче чара – санау интонациясе.
- Схемасы:[1], [2].